ГЛАВА ВЕРХНЕОШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская д.54 а, с.Верхняя Ошма, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422163

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ УШМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет ур., 54 а нче йорт, Югары Ушма авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422163

тел.(факс): (85563) 2-32-36; e-mail: Voshm..Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар | Постановление
"01 " ноябрь 2019 ел. | № 13

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлегенең Комазан Урманчылыгы поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Югары Ушма авыл җирлеге муниципаль берәмлеге" Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Комазан Урманчылыгы поселогы, Мәктәп урамы , 8а нче йорт янында 2019 елның 15 нче ноябрендә сәгать 10.00 . Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлегенең Комазан Урманчылыгы поселогы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлегенең Комазан Урманчылыгы поселогы,торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- вак таш җәеп, юлларны ремонтлау:
(сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү)

-Югары Ушма һәм Комазан Урманчылыгы торак пунктлары арасындагы юллар.

- Комазан Урмачылыгы торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге башкарма комитетына Комазан Урманчылыгы поселогы,гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Югары Ушма авыл җирлеге башлыгы: И.З.Исмэгыйлев